РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ БОЛЬШЕШИНАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ШЫҢАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422054, Республика Татарстан,
Сабинский район,с.Большой Шинар,
ул. Кооперативная,дом 36
тел. (84362) 41-2-11

422054, Татарстан Республикасы,
Саба районы,Олы Шыңар авылы,
Кооператив урамы, 36 йорт
тел. (84362) 41-2-11

e-mail: bshin.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
25.04.2025

КАРАР
№11

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 30нчы апрелендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге җирле үзидарә органнарыныңдепутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт ечен түләү шартлары турында Нигезләмә " турында 9нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.03.2018 елгы 182нче номерлы "Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, рәисләрнең, рәис урынбасарларының, муниципаль берәмлекләрнең тикшерү-исәп аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында" карарына үзгәрешләр турында" 30.04.2024 ел 290нчы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының 30.04.2018 елда 9нчы номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә" карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгече вазифа окладын 15389 сум күләмендә расларга.»;

1.2. 1нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә, әлеге карар ечен 1нче кушымта нигезендә җиткерергә.

2. Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының 30.04.2018 № 9 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларына, сайланулы

вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә”гә   түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 2.3. пунктта «акчалата кызыксындыруның 1,072 елеше күләмендә” дигән сүзләрне «акчалата кызыксындыруның 1,29 өлеше күләмендә” дигән сүзләр белән алыштырырга;

2.2. 3.5.4 пунктының икенче җөмләсендә “ 41 процент” сүзен  “ 58 процент” сүзе белән алмаштырырга;

2.3. 7.1. пунктының 5) подпунктында  «18 процент» сүзен “ 58 процент”  сүзе белән алмаштырырга;

2.4. 6.1. пунктының 2) подпунктында «4,65 айлык акчалата бүләк» сүзләрен ««12,86 айлык акчалата бүләк » сүзләре белән алыштырырга.

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына, әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, 2025 елның 1 маеннан гамәлдә булу башлангач, яңа штат расписаниеләрен расларга.

4. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү, тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

5. Әлеге карар 2025нче елның 1 маеннан  үз кеченә керә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru һәмТатарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/ shinar адреслары буенча бастырып чыгарырга.

7. Карарның үтәлешен тикшерүне үз өстемә алам.

Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгы А.Г.Гарипов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Олы Шыңар авыл җирлеге Советының
2025елның 25нче апреле,
11нче номерлы карарына
1 нче кушымта

Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының акчалата бүләкләре күләме

| Вазыйфалар исемнәре акчалата бүләк күләме (сумнарда) | акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Авыл җирлеге башлыгы | 20 091 |
| Депутатлар | 15 389 |
| Сайланулы вазыйфаи затлар | 15 389 |